БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** — **КАРАР**

1 ноябрь 2018 ел — № 149

**Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республика законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар **итте:**

1. Балтач район Советының 2015 елның 11 августындагы 294 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары Н Н.Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе — Р.Р.Нотфуллин

01.11.2018 елгы № 149
Татарстан Республикасы
Балтач район Советы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

**1.Нигезләмәнең 8-нче пунктының 1-нче пунктчасының “в” өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

“в) муниципаль хезмәт стажы кимендә ике ел яки белгечлек буенча кимендә дүрт ел эш стажы;”.

**2. Нигезләмәнең 8-нче пунктының 1-нче пунктчасының “г” өлешен түбәндәге редакңиядә бәян итәргә:**

«г) идарә эшчәнлеге тәҗрибәсе кимендә биш ел. Идарә итү эшчәнлеге дигән өлештә оешма җитәкчесе, оешма җитәкчесе урынбасары, дәүләт органы, муниципаль орган вазыйфаларында, шулай ук аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларында эш аңлашыла;».

**3. Нигезләмәнең 12-нче пунктындагы 9-нчы пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

“9) муниципаль хезмәткә урнашу елы алдындагы бер ел эчендә үз керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы белешмәләрен һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

**4. Нигезләмәнең 12-нче пунктын 11-нче пунктча белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:**

«11) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъвачы граждан һәркем файдалана алырлык мәгълүматны, шулай ук аларны танырга мөмкинлек бирүче белешмәләрне урнаштырган “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтларның һәм (яисә) сайтлар сәхифәләренең адреслары турында хезмәткә кергәндә муниципаль хезмәткә керү елына кадәрге өч календарь ел өчен бирә.».